Шифр ТЯ10-10

Задания регионального этапа
Всероссийской олимпиады школьников
по татарской литературе
2017-2018 учебный год
10 класс

Уважаемый участник!

Время проведения олимпиады по татарской литературе в 9-11 классах – 180 минут. Максимальное количество баллов – 50 баллов.

Ответы на задания I *части* заносятся в таблицу ответов.

| Инструкция по выполнению работы |
|---|
| При выполнении заданий в Таблице ответов под номером выполняемого вами задания поставьте знак «Х» в клеточку, которая соответствует букве выбранного вами ответа. |

Таблица ответов

| | 1.1 | 1.2 | 1.3 | 1.4 | 1.5 | 1.6 | 1.7 | 1.8 | 1.9 | 1.10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1) | | | | | | | | | | |
| 2) | | X | X | | X – | X | X | | X | X – |
| 3) | X | | | X | | | | X | | |
| 4) | | | | | | | | | | |
| Задания по 1 баллу 8б. | | | | | | | | | | |

| 1. | Тестлар (дөрес җавапны билгеләгез) | 10 |
|---|---|---|
| 1.1. | “Исемдә калганнар” әсәренең авторы<br>1) А.Гыйлаҗев;<br>2) Г.Исхакый;<br>3) Г.Тукай;<br>4) М.Әмир. | 1 |
| 1.2. | Татарларның юкка чыгу куркынычы турындагы әсәр исемен билгеләгез:<br>1) “Татар кызы”;<br>2) “Ике йөз елдан соң инкыйраз”;<br>3) “Сөннәтче бабай”;<br>4) “Җан Баевич”. | 1 |
| 1.3. | “Зәңгәр шәл” драмасының төп герое:<br>1) Хәдичә;<br>2) Мәйсәрә;<br>3) Галиябану | 1 |
| 1.4. | М.Җәлилгә Советлар Союзы Герое исеме бирелде<br>1) 1945 елда; | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | 2) 1950 елда;<br>3) 1956 елда. | |
| 1.5. | “Кисекбаш” балетының авторы<br>1) Ф. Яруллин;<br>2) Р. Гөбәйдуллин;<br>3) Ә. Бакиров. | 1 |
| 1.6. | “Ремарка” сүзенә туры килгән билгеләмәне табыгыз.<br>1) кечкенә күләмле, эмоциональлеге, ритмик төзелеше белән шигъри сөйләмгә якын булган, лирик-патетик характердагы проза әсәре;<br>2) драма әсәрләрендә катнашучыларның тышкы кыяфәтен, кием-салымын, үз-үзләрен тотышын, сөйләү рәвешен, уен бара торган күренешне, урынны яки вакытны аңлатып биргән сүзләр;<br>3) әкият нигезендә, лиро-эпик әсәр нигезендә язылган жанр төре;<br>4) татар халык авазы иҗатына кергән әсәрнең жанр төре. | 1 |
| 1.7. | Г.Тукайның “Печән базары, яхуд Яна Кисекбаш” әсәре нинди жанрда язылган?<br>1) драма;<br>2) поэма;<br>3) мәсәл. | 1 |
| 1.8. | Төмән өлкәсенең күренекле язучысы Якуб Зәнкиевның “Иртеш таңнары” романы кайчан һәм кайда басылып чыга?<br>1) 1992 елда Уфада;<br>2) 1993 елда Төмәндә;<br>3) 1994 елда Казанда. | 1 |
| 1.9. | Искәндәр, Галия, Вәли, Кадрия, Рафаэль...<br>Бу геройлар кайсы әсәрдән?<br>1) Г.Ибраһимов “Тирән тамырлар”.<br>2) Г. Кутуй “Тапшырылмаган хатлар”.<br>3) Г.Исхакый “Ул әле өйләнмәгән иде”. | 1 |
| 1.10. | Муса Акъегетнең “Хисаметдин менла” әсәрендә күтәрелгән тема -<br>1) гаделлек;<br>2) рухи мирасны саклау;<br>3) милләтнең артталыгын бетеру. | 1 |
| 2. | Бирелгән өзекләрнең авторларын, нинди әсәрләрдән алынганлыгын күрсәтегез. | 10 |
| 2.1. | “Мәдрәсәдә бар иде бер таз малай,<br>Бик шаян, шуклык белән мөмтаз малай”.<br>________________________________________ | 2 – |
| 2.2. | “... Нурлы кояш, тулган ай һәм унбер йолдыз<br>Шул төшемдә сәҗдә кылды мина төп-төз,<br>Бу төшемне шулай курдем, һичбер шиксез...”<br>Кол Гали „Кыйссаи Йосыф“ | 2 + |
| 2.3. | “ Әнкәй орышты тимер ук өчен, | 2 – |

| | | |
|---|---|---|
| | Әнкәй орышты бигрәк юк өчен.<br>Җимнәр ташыйдыр кошлар басудан,<br>Әнкәй каргады безне ачудан"<br>Бирелгән өзекнең исемен, жанрын языгыз. | |
| 2.4. | "... Ишек алдына йөгереп чыксам, шатлыгымнан телдән кала яздым. Әнә ул, әнә мин көткән колын! Үзе жирән, аркасыннан бармак киңлеге коңгырт тасма сузылып киткән, алгы аякларының балтырына тикле ак оек кигән..."<br>„Алмачуар" Г. Ибраһимов, хикәя | 2 |
| 2.5. | "Менә, ниһаять, җомга да килеп житте. Тагын бер сикерәсе дә шимбәне узасы, аннан - якшәмбе. Базар көн. Урыс атнасы. Төрле-төрлечә атап йөртәләр ул көнне. Якшәмбедә - Сабантуй ..." | 2 |
| 3. | Бирелгән юлларны дәвам итәргә, авторларын, әсәрләрнең исемен курсәтергә. | 10 |
| 3.1. | Түзәлмәдем, бардым җырлаучыга,<br>Дидем: " Кардәш, бу көй нинди көй?<br>Җавабында ишетмешенең миңа:<br>„Бу көй була, диде, Әлләки"<br>Габдулла Тукай „Милли моңнар" | 5 |
| 3.2. | И телем, сансыз гасырны...<br>Исән-сау кичкән телем!<br>Сахралар теле тирән син,<br>Куркулар теле бирен.<br>Хәсән Туфан „Татар теле турында җырлар" | 5 |
| 4 | Төшенчәләрне аңлатыгыз. | 10 |
| 4.1 | Хикәя төшенчәсенә аңлатма бирегез. Аңа хас сыйфатларны күрсәтегез. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез.<br>Чынлык белән язылган кечкенә күләмле әсәр/жанр. Бер сюжет. Вакыйгалар күп түгел. Геройның бер сыйфатын, кисене тасвирый.<br>Мисалы: Г. Ибраһимовның „Алмачуар", Г. Исхакыйның „Кәҗүл читек". | 5 |
| 4.2 | Повесть төшенчәсенә аңлатма бирегез. Аңа хас сыйфатларны күрсәтегез. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез.<br>Чынлык белән язылган, хикәя белән роман арада күләмле жанр. Сюжеты бер (бер яки ике). Вакыйгалар романнан азрак, хикәядән артыграк.<br>Мисалы: Мирсәй Әмирнең „Агыйдел" повесте, Галимҗан | 5 |

<table>
<tr><td></td><td>Бәшировның „Туган ягым - яшел бишек" повесте</td><td></td></tr>
<tr><td>5</td><td>Иҗади бирем.<br><br>Шагыйрь Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» циклына кергән шигырьләре хакында нәрсә беләсез? Әлеге циклга кергән шигырьләреннән мисаллар китерегез. Бу «дәфтәр»нең әһәмияте нидән гыйбәрәт? – фикерегезне дәлилләп инша формасында языгыз.<br>Муса Җәлил. Зур исемле кеше. Халык каһарманы. Бөек шагыйрь һәм язучы. Татар әдәбияты күренекле әдипләренең берсе. Үз Ватанын бик яраткан кеше. Советлар Союзы Герое. Һәм гади татар егете.<br>Җәлил әсәрләре – татар матур әдәбиятының мирасы. Алар күп телләргә тәрҗемә ителгәннәр. Кем генә Җәлил шигырьләре белән таныш түгел? „Кызыл ромашка", „Вәхшәт", „Кичер, Илем!", „Бер үгет", „Ышаныч", „Җырларым" һәм бик күп данлыклы шигырьләр. Күбесе „Моабит дәфтәрләре" җыентыгына кергәннәр.<br>Минемчә, „Моабит дәфтәрләре" – иң данлыклы Муса Җәлилнең җыентыгы. Ни өчен? Беренчедән, бу дәфтәр Сталин вафат булуыннан гына безнең якка килде, чөнки шагыйребезне „Враг народа" атаганнар. Сугыштан соңгы вакытларда күп кешеләр дөресез түгел „Враг народа" булганнар. Әмма без беләбез: Муса Җәлил „Враг народа" булмаган һәм булмас иде, чөнки ул үз Ватанын бик ярата иде. Һәркемгә билгеле: дәфтәрләр ~~[illegible]~~ Рәсәйгә Андре Тиммерманс белән килгәннәр. Һәм бу шигырьләр данлыкларның һәм уңышларының берсе.<br>Ә ни өчен Муса Җәлилнең мондый данлыклы әсәрләр, дәфтәрләрдә генә түгел? Ни өчен Муса Җәлилне һәр татар кеше генә түгел, ә күп төрле халыклар белә? Бу сорауларга гади җавап: аның иҗаты үз Ватанга мәхәббәт хисләр белән данлыклы. Шуңа күрә халык аларны ярата һәм зурлый. Шигырьләрдән бер-ике дүртьюллыкны һәр укучы белергә тиеш һәм белә.<br>Җырларым, сез шытып йөрәкләрдә<br>Ил кырында чәчәк атыгыз!<br>Күпме булса сездә көч һәм ялкын<br>Шулкадәрле җирдә хаклысыз!<br>Бу юллар ~~[illegible]~~ Җәлилнең яраткан шигырьдән: „Җырларым". Бу да шигырь „Моабит дәфтәрләре"нә керә. Бу юлларда Җәлил күрсәтә: туган татар</td><td>10</td></tr>
</table>

продолжение →

җырлары аның рухын канатлана, көч бирә.
1957 елда „Моабит дәфтәрләре“ Ленин премиясе белән бүләкләнде.

10б.

40б.